Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чистай Выселкасы авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

13.02.2020 № 84/2

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Чистай Выселкасы авыл җирлеге Советының
2019 елның 05 июнендәге
«Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
«Чистай Выселкасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә
муниципаль хезмәт турында»гы
72/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Чистай шәһәр прокурорының 2020 елның 24 гыйнварындагы 02-08-02-2020 номерлы протестын карап чыкканнан соң, «Россия Федерациясе Хезмәт Кодексына хезмәт эшчәнлеге турындагы мәгълүматларны электрон рәвештә формалаштыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 декабрендәге 439-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, “Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында”гы 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы федераль закон белән, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 2019 елның 27 декабрендәге 118-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Чистай муниципаль районы Чистай Выселкасы авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай Выселкасы авыл җирлеге Советының 2019 елның 05 июнендәге «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай Выселкасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында»гы 72/1 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 4 статьяда:
6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6. 2020 елның 1 октябренә кадәр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (секретаре) вазыйфасын биләү өчен, һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре урта һөнәри белем һәм муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына - кимендә ике ел, яисә өч ел булу билгеләнә. 2020 елның 1 октябреннән әлеге статьяның 2 пунктының 1 пунктчасында каралганча, күрсәтелгән вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре 2020 елның 1 октябренә кадәр вазыйфага билгеләнгән һәм әлеге пунктта каралган тиешле квалификация таләпләренә карата кулланылмый.»;

7 пунктта «2019 елның 1 гыйнвары» сүзләрен «2022 елның 1 гыйнвары» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 6 статьяның 22 пунктында “хезмәт кенәгәсен” сүзләрен «хезмәт кенәгәсенә һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларга” сүзләренә алмаштырырга»;

1.3. 12 статьяның 1 пунктында:

2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән

беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә, коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында катнашу (конференция), яллаучы вәкиле рөхсәте белән түләүсез нигездә катнашу;

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә, муниципаль берәмлек идарә органнарында һәм Ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) булган оешманың идарә итү органнарында һәм Ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен бушлай тәкъдим итү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;»;

түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт белән тулыландырырга:

«2.1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;»;

1.4. 13 статьяның 3 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат, хезмәт килешүе беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;»;

1.5. 19 статьяның 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 17, 18 һәм 32 статьяларында каралган түләтүләр, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча эшкә яраксызлыгы, ялында булу чорларын санамыйча, муниципаль хезмәткәр тарафыннан коррупциячел хокук бозу кылу турында мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча һәм коррупциячел хокук бозу кылган көннән өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән вакытка җинаять эше вакыты кертелми.»;

1.6. 20 статьяның 2 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларны алып бару;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм авыл җирлеге халкының күмәк җыелу урыннарында, игълан итү стендларында һәм такталарына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай Выселкасы авыл җирлеге
башлыгы В.В.Малышев